СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

“26” ноябрь 2018 нче ел № 98

**“2018 нче елның 3 нче июлендәге “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 43 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”**

2018 нче елның 19 нчы июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында” 204-ФК нче номерлы Федераль канунның дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешенә” , 2017 нче елның 29 нчы декабрендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләре күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү мөмкинлеген беркетү өлешендә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында” 479-ФК номерлы Федераль канунга нигезләнеп, **карар бирәм:**

1. 2018 нче елның 3нче июлендәге “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 43

нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карарына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

- 2018 нче елның 3нче июлендәге "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 43 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карарына 1-10 кушымтаның 5 нче бүлеген түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 2018 нче елның 19 нчы июлендәге 204-ФК нче номерлы Федераль канунның 1 маддәсе 8 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә шикаятьне канәгатьләндерелергә тиешле дип танылган очракта, 2018 нче елның 19 нчы июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 204-ФК нче номерлы Федераль канунның 16 маддәсе 1.1 өлешендә каралган дәүләт хезмәте күрсәтүче Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган житешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу итү сорала һәм гариза бирүчегә дәүләт хезмәте алу максатларында алга таба башкарылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 2018 нче елның 19 нчы июлендәге 204-ФК нче номерлы Федераль канунның 1 маддәсе 8 өлешендә күрсәтелгән гариза бирүчегә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән

аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә";

- 2018 нче елның 3 нче июлендәге "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 43 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карарына 1-10 кушымтаның 5 бүлеге 5.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- "5.2. Шикаять кәгазьдә язмача формада, электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтүче яки муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәк яки Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы гавами-хокукый җирле үзидарә органына (алга таба-күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 2017 нче елның 29 нчы декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүне күпфункцияле үзәкләрендә бирү мөмкинлеген беркетү өлешендә Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 479-ФК нчы номерлы Федераль канунның 16 маддәсе 1.1 өлеше белән күрсәтелгән оешмаларга бирелә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр югары органга (булган очракта) бирелә яисә булмаганда, турыдан-туры дәүләт хезмәте күрсәтүче Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан карала. Күп функцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә тапшырыла. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күп функцияле үзәкне гамәлгә куючыга яисә Татарстан Республикасы норматив хокукый акты белән вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла. 2017 нче елның 29 нчы декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында мөрәҗәгать

итүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүне күпфункцияле үзәкләрендә бирү мөмкинлеген беркетү өлешендә Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 479-ФК нчы номерлы Федераль канунның 16 маддәсе 1.1 өлеше белән күрсәтелгән оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бу оешмаларның җитәкчеләренә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының дәүләт хезмәте күрсәтүче җирле үзидарә органнарының, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарының дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрнең, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органы җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта белән, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк аша, дәүләт хезмәте күрсәтүче Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органының рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хемәтләренең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хемәтләренең региональ порталы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителә.

2017 нче елның 29 нчы декабрендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында гариза бирүче тарафыннан бердәм гариза бирү юлы белән берничә дәүләт (муниципаль) хезмәтләрен күрсәтүне күпфункцияле үзәкләрендә бирү мөмкинлеген беркетү өлешендә Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында" 479-ФК нчы номерлы Федераль канунның 16 маддәсе 1.1 өлеше белән күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта белән, "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникация челтәреннән файдаланып,әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хемәтләренең бердәм порталы яки дәүләт һәм муниципаль хемәтләренең региональ порталы аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында

кабул ителә”.

- 2018 нче елның 3 нче июлендәге “Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 43 нче номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы карарына 1-10 кушымтаның 5.1 нче пунктында 2 нче кызыл юлны түбәндәге эчтәлек белән тулыландырырга:

-“Дәүләт хезмәте күрсәткәндә 2018 нче елның 19 нчы июлендәге дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында” 204-ФК нче номерлы Федераль канунның 7нче маддәсе 1 нче өлешенең 4 нче пунктында каралган очраклардан тыш, гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда документларның булмавы һәм (яисә) дөрес булмавы һәм (яисә) төгәллеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар таләп итү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелгән күпфункцияле үзәккә 2018 нче елның 19 нчы июлендәге “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль канунга үзгәрешләр кертү хакында” 204-ФК нче номерлы Федераль канунның 16 маддәсендәге 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр алганда гражданнарның өстәмә гарантияләрен билгеләү өлешендә тулы күләмдә тиешле дәүләт хезмәтләре күрсәтү вазыйфасы йөкләнгән булса”;

2. Әлеге карарны “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында” “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә һәм Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль**
**Районы Башлыгы** **Козлов В.М.**